СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.12.2021 с. Верхний Услон № 18-226

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы Рәисенең, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 апрелендәге 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына, "Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына, Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Расларга:

- Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре (1 нче кушымта);

- тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру һәм күләме тәртибе (2 нче кушымта);

- муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру һәм күләме тәртибе (3 нче кушымта);

- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләрне гамәлгә ашыру һәм түләү күләмнәре тәртибе (4 нче кушымта);

- айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (5 нче кушымта);

- муниципаль хезмәткәргә класс чины өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (6 нчы кушымта);

- еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (№7 кушымта);

- матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләме (8 нче кушымта);

- нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәплләү турында

нигезләмә (9 нчы кушымта);

- төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләүне (юридик эш өчен өстәмә) гамәлгә ашыру күләмнәре һәм тәртибе (10 нчы кушымта);

- профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм күләме (11 нче кушымта);

- Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (12 нче кушымта);

- дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (13 нче кушымта).

- Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары һәм Югары Ослан муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләк күләме (14 нче кушымта);

- Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондын формалаштыру күләме һәм тәртибе (15 нче кушымта).

2. Билгеләргә:

2.1. Муниципаль район Башлыгына, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата түләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләкләүләр, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарыла ала. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы Министрына айлык акчалата түләүләрнең 0,9 артмый.

2.2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә вазифа окладының күләме муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә. Шул ук вакытта муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең айлык акчалата күләме муниципаль район Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең 0,6 артмаска тиеш.

2.3. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасарына ай саен акчалата бүләк һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган акчадан тыш, ай саен акчалата бүләк, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә түләнә ала. Шул ук вакытта Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасарына айлык акчалата түләүләр күләме Югары Ослан муниципаль районы Башлыгына айлык акчалата түләү күләменең 0,55 артмаска тиеш.

2.4. Югары Ослан муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенә ай саен акчалата бүләк һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләк, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә түләнә ала. Шул ук вакытта Югары Ослан муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенә айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме Югары Ослан муниципаль районы Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең 0,55 артмаска тиеш.

3. Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек кабул ителгән хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

4. «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 33-362 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиятдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Советының 2021нче елның
27нче декабреннән 18-226нчы номерлы
карары белән расланган карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 29895 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 27135 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 27135 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 26905 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 26790 |
| Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче | 25180 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 24606 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы бүлеге башлыгы | 20927 |
| Совет, Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге җитәкчесе урынбасары, башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары, район башлыгы ярдәмчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 18283 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы баш белгече | 16212 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы әйдәп баручы белгече | 15063 |

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
2 кушымта

Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру һәм күләме тәртибе

1. Муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә муниципаль хезмәт стажына бәйле рәвештә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажында | Өстәмә күләме (процентларда) |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 һәм аннан да күбрәк ел | 20 |

2. Муниципаль хезмәт стажы, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү өчен, анда муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торган җирле үзидарә органы акты белән билгеләнә.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
3 кушымта

Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру һәм түләү күләмнәре тәртибе

1. Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмәләр муниципаль хезмәткәргә биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы төркеменә җирле үзидарә органының норматив акты белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәтнең һөнәри әзерлеген, белгечлеге һәм биләгән вазыйфасы буенча эш тәҗрибәсен исәпкә алып билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен өстәмә түләү түбәндәге шартларның берсе булган очракта түләнә:

1) җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән төзелгән комиссияләр, коллегияләр яисә консультатив иҗтимагый советлар эшендә катнашу;

2) идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсенә ия булу (җитәкче вазыйфаларда, муниципаль хезмәт вазыйфаларында яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында эш стажы булу) кимендә өч ел;

3) турыдан-туры норматив хокукый актлар проектларын әзерләү белән бәйле эшләрне башкару.

3. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен өстәмә түләү аның күләмен тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты белән билгеләгән көннән түләнә.

4. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен өстәмә муниципаль хезмәткәрнең акчалата кереме белән бер үк вакытта түләнә.

5. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Биләгән вазыйфалар төркеме | Вазыйфаи окладка айлык өстәмә күләмнәре процентларда |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | 9 |
| Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | 7 |
| Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары | 5 |
| Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 3 |
| Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары | 1 |

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
4 кушымта

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен
премияләрне түләү тәртибе һәм күләме

1. Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өчен аларның җаваплылык дәрәҗәсен арттыру, башкарыла торган бурычларның сыйфатын күтәрү, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы үтәү максатларында, җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә максималь күләмдә чикләнмәгән аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр бирелә ала.

2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләү муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, әлеге Тәртип нигезендә кабул ителгән җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе карары буенча вазифа инструкциясен үтәүне исәпкә алып башкарыла.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән муниципаль хезмәткәрнең акчалата керемен түләү белән бер үк вакытта аның күләмен җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты белән билгеләгәннән соң түләнә.

2.1. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы тәкъдиме буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан һөнәри бәйрәмнәре һәм бәйрәм даталары (җирле үзидарә көне, Сабантуй, Республика көне, Яңа ел һ.б.) уңаеннан муниципаль хезмәткәрләргә премияләр бирелә ала.

3. Премияләр яллаучы (эш бирүче) муниципаль хезмәткәргә җирле үзидарә органының яки муниципаль органның хезмәт өчен түләү фондында каралган акчалар чикләрендә түләнә һәм аларга карап билгеләнә:

- тиешле җирле үзидарә органына йөкләнгән бурычларны, функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча хезмәткәрнең шәхси кертеме;

- хезмәткәр тарафыннан биремнәрне үтәүнең катлаулылыгы, мөһимлеге һәм сыйфаты, ирешелгән нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе;

- хезмәткәр тарафыннан вазифа инструкциясен үтәү нәтиҗәләре;

- хезмәт дисциплинасын үтәү.

4. Муниципаль хезмәткәрләргә үз вазыйфаи бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен премия тулысынча яки өлешчә түләнмәскә мөмкин.

Шул ук вакытта вазыйфаи бурычларны үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү фактлары документлар белән расланган булырга тиеш.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
5 кушымта

Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләк тә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесенең вазыйфаи окладның 1 % артмаган күләмдә җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән билгеләнә, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына азрак вазыйфаи оклады белән биләгән муниципаль хезмәткәр структурасын үзгәртеп корганда билгеләнү очрагы керми, ул элек биләгән хезмәт хакыннан кимрәк булган муниципаль хезмәт хакы белән, шул ук вакытта муниципаль хезмәткәрне акчалата бүләкләү күләмен элек биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
6 кушымта

Муниципаль хезмәткәргә класс чины өчен айлык өстәмә
гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

Муниципаль хезмәткәргә класс чины өчен айлык өстәмә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Класс чины | Класс чины өчен өстәмә түләү күләме (вазыйфаи окладка карата процентларда) |
|---|---|
| 1 класслы гамәлдәге муниципаль киңәшче | 7 |
| 2 класслы гамәлдәге муниципаль киңәшче | 5 |
| 3 класслы гамәлдәге муниципаль киңәшче | 3 |
| 1 класслы муниципаль киңәшче | 7 |
| 2 класслы муниципаль киңәшче | 5 |
| 3 класслы муниципаль киңәшче | 3 |
| 1 класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 7 |
| 2 класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 5 |
| 3 класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 3 |
| 1 класслы муниципаль хезмәт референты | 7 |
| 2 класслы муниципаль хезмәт референты | 5 |
| 3 класслы муниципаль хезмәт референты | 3 |
| 1 класслы муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| 2 класслы муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| 3 класслы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

Муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәткәр элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган очракта, аның класс чины өчен оклад күләмен аның биләгән вазыйфасы кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин биргәнчегә кадәр исәпләп чыгару вазыйфаи окладның процент ставкасыннан 3 процентка тигез була.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасына элек биләгән вазыйфаларның түбәнрәк төркеменә караган һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән очракта, класслы чин өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып башкарыла, ул 7 процентка тигез.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
7 кушымта

Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

1. Муниципаль хезмәткәрләргә ел саен түләнә торган отпуск биргәндә, 1,2 вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә бер тапкыр бирелә торган түләү башкарыла.

1.1. Район Башлыгына, район Башлыгы урынбасарына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына бер айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә.

2. Еллык түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә өлешләр буенча бирелә икән, бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәр теләге буенча отпускның бер өлешен биргәндә башкарыла.

3. Аерым очракларда, муниципаль хезмәткәр гаризасы нигезендә, бер тапкыр бирелә торган түләү өлешләп башкарылырга мөмкин.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
8 кушымта

Матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләме

1. Матди ярдәм түләү муниципаль хезмәткәрнең хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризасы нигезендә башкарыла.

2. Аерым очракларда матди ярдәм җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан бала туганда, тантаналы, юбилей датасына карата, шулай ук хезмәткәр һәм аның якын туганнары каты авыру, үлем һәм башка бәхетсезлек очракларында өстәмә рәвештә түләнергә мөмкин.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
9 кушымта

## Нормага салынмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләүләрен билгеләү, исәпләү һәм түләү шартларын билгели.

### 2. Түләү билгеләү тәртибе һәм шартлары

2.1. Хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләү муниципаль хезмәтнең югары, төп һәм әйдәп баручы вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә 2 процент күләмендә билгеләнә, аларның саны һәм исемлеге район Башлыгының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.

2.2. Түләү ай саен башкарыла, һәм ул, җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары хисабына, акча белән бергә, түләнә.

2.3. Муниципаль хезмәткәрләргә түләү билгеләү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, ә Башкарма комитет Җитәкчесенә - район Башлыгы тарафыннан түләү билгеләү турында Карар кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
10 кушымта

Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау кирә торган муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләүне гамәлгә ашыру күләмнәре һәм тәртибе (юридик эш өчен өстәмә)

1. Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау кирә торган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча гамәлгә ашырыла.

2. Түләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары хисабына акча белән бергә түләнә.

3. Юридик хезмәт өчен айлык түләүләр вазыйфаи оклад буенча процент ставкаларының түбәндәге күләмнәрендә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме | Вазыйфаи окладларга процент ставкалары күләме |
|---|---|
| муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | 6 |
| муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 2 |

4. Күрсәтелгән түләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча муниципаль хезмәткәрнең эш характерын үзгәрткәндә үзгәртелергә яисә юкка чыгарылырга мөмкин.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
11 кушымта

Профиль фәнни дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

1. Өстәмә билгеләү өчен нигез булып муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган профильле гыйльми дәрәҗәсе булу тора.

Профильле гыйльми дәрәҗә буенча таләпләр җирле үзидарә органнары функцияләре белән билгеләнә һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Берничә нигез буенча аны алу хокукына ия муниципаль хезмәткәрнең гыйльми дәрәҗәсе өчен өстәмә муниципаль хезмәткәр теләге буенча бер нигез буенча билгеләнә. Өстәмә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе өчен-вазыйфаи окладның 1,5 проценты;

б) фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2 проценты.

3. Өстәмә исәпләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары хисабына хезмәт хакы белән бергә түләнә.

4. Өстәмә гыйльми дәрәҗә бирүне раслаучы тәкъдим ителгән документ нигезендә билгеләнә. Муниципаль хезмәткәргә өстәмә билгеләү турындагы актның гамәлдә булуы әлеге карар гамәлдә булган очракта, аның вазыйфасында эшләгән бөтен чорына кагыла.

5. Муниципаль хезмәткәргә өстәмә билгеләү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе - муниципаль район Башлыгы тарафыннан профильле гыйльми дәрәҗә таләпләренә туры китереп кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
12 кушымта

Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

1. Муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган Татарстан Республикасының мактаулы исеме булуы өстәмә билгеләү өчен нигез булып тора.

2. Татарстан Республикасының мактаулы исеме булган муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә билгеләнә.

Берничә нигез буенча аны алу хокукына ия муниципаль хезмәткәргә Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен өстәмә муниципаль хезмәткәр теләге буенча нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

3. Өстәмә исәпләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органы (Муниципаль орган) хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән хезмәт хакы белән бергә түләнә.

4. Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә түләү билгеләү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе-муниципаль район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
13 кушымта

Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме

1. Дәүләт серенә кертелгән муниципаль хезмәткәрләр өчен дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмәләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнергә мөмкин:

- «аерым әһәмияткә ия» серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләү өчен-вазыйфаи окладның 50-75 проценты;

- «бөтенләй яшерен» яшеренлек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен-вазыйфаи окладның 30-50 проценты;

- тикшерү чараларын үткәрүгә рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен» сер итеп бирелгән мәгълүматлар белән эшләү өчен-10-15 процент, тикшерү чараларын үткәрмичә-вазыйфаи окладның 5-10 проценты;

- дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен:

1 елдан 5 елга кадәр - вазыйфаи окладның 10 проценты;

5елдан 10 елга кадәр - вазыйфаи окладның 15 проценты;

10 елдан һәм өлкәнрәк - вазыйфаи окладның 20 проценты.

Күрсәтелгән өстәмәләр законда билгеләнгән тәртиптә яшеренлек дәрәҗәсе белешмәләренә рөхсәт алган вазыйфаи затларга түләнә.

2. Түләү ай саен җирле үзидарә органы җитәкчесе карары нигезендә башкарыла һәм бер үк вакытта муниципаль хезмәткәрнең акчалата керемен җирле үзидарә органына хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
14 кушымта

Муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Башлыгы урынбасары, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисе акчалата бүләк күләмнәре

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 30442 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 27398 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 27398 |

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2021нче елның 27нче декабреннән 18-226нчы номерлы карары белән расланган карарына
15 кушымта

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалардан тыш, түләү өчен акча каралган (бер елга исәпләгәндә):

1) класс чины өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен айлык өстәмә түләү - вазыйфаи окладларның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр-вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү - вазыйфаи окладларның ун проценттан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү-вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

7) хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.